1990 елның
1 июленнән чыга

Заман сулышы

Чәршәмбе
3
февраль, 2016

(«Дыхание времени». Лениногорск)
№7 (4231)

4 февральгә һава торышы: кар, температура көндез +1, төнлә –1

Тырыш халык яши

Федотовка балалар бакчасына 14 сабый йөри, февраль аенда тагын бер бала килер дип көтәләр

«Федотовкага килгәндә, без – район җитәкчелеге, тыныч күңел белән киләбез. Биредә уңган, тырыш халык яши. Аграр предприятие булган җирдә аның ярдәмен дә күрергә була», диде район башлыгы Рәгать Хөсәенов әлеге авыл җирлегендә узган җыенда.

Розалия МОСТАФИНА

Әлеге җирлектә һәр елны яңа бурычлар билгеләп башлыйлар. Дөрес, алга куелганның барысы да үтәлә дигән сүз түгел. Аның өчен мөмкинлек тә, гамәлгә кую алымы да кирәк. Авыл җирлеге башлыгы Валентина Павлова әйтүенчә, узган ел күләмле эшләр башкарылган. Әлеге җирлеккә караган Кузьминовкада Мәктәп урамы юллы булган: вак таш җәйгәннәр, ә Федотовкада Югары урам ремонтланган. Андагылар рәхәткә тиенгәндер, менә Түбән урамда яшәүчеләр җыенда зарланып алдылар: «Барлык су агымы безнең урамга төшә, сазлыкка әйләнә, трактор да керә алмый», диләр. Язгы якта ташудан сакланыр өчен Гадәттән тыш хәлләр идарәсенә хат әзерләргә кушылды. Авыл юлларын ремонтлау киләчәккә дә билгеләнгән: Мурашев, Нагорная, Новая, Кооперативная урамнары үз чиратын көтә. Кыш айларында урамнар чистартылмыйча калмый, Кузьминовканы да онытмыйлар. Монда шулай ук шәхси хуҗалыклардагы тракторлар ярдәмгә килә, хуҗалык тракторы да чыккалый икән.

Урам утлары да ел саен арта барып, яктырта. Хәзерге вакытта Федотовкада 46 фонарь, Кузьминовкада 13 ноктада лампочкалар яна. Быел да куйганнар. “Киләчәктә дә куйдыртсак, яхшы булыр иде. Үзара салым акчасының бер өлешен моңа тотарбыз”, ди Валентина Павлова.

Җиңү бәйрәменең 70 еллыгы уңаеннан һәйкәлләр яңартылып, сугыш чоры балаларына, тыл хезмәтчәннәренә стеллалар куелган.

Сәламәт яшәү юнәлешендә дә алга китеш бар. Хоккей корты турында күптән хыялланган булганнар, теләк чынга ашкан. Әле эшләнәсе эшләре күп, мәсәлән, асфальт җәю, суга скважина казыту. Бу уңайдан “Татнефть” җитәкчелегенә хат аша мөрәҗәгать иткәннәр инде. Спорт инвентарьлары: тимераяк, кәшәкәләре бар. Корт кибет артында урнашкан. Димәк, киләчәктә Федотовка егетләре өчен хоккей уйнарга урын булачак.

Балалар бакчасы мәктәпнең бер «канаты»нда урнашкан, алар монда 2008 елда күчкән. Бакчага 14 сабый йөри. «Февраль аенда тагын бер бала киләчәк дип көтәбез. Исән-сау йөрсеннәр, без балаларның булуына шат», ди бакча мөдире Гүзәлия Кирилова.

Мәктәптә 43 бала укый. Быел түбәсенә капиталь ремонт планлаштырылган.

Ахыры 2 нче биттә

КИЧӘ БҮГЕН ИРТӘГӘ

Ветераннар эшчәнлеге бәяләнде

Шәһәр һәм район ветераннар советына ветераннарны социаль яклау белән тәэмин итүдә һәм яшьләрне патриотик тәрбияләүдә зур өлеш керткәннәре өчен Россия Федерациясе Советы рәисе Валентина Матвиенкодан Рәхмәт белдерелгән.

“Трудовая доблесть России” иҗтимагый оешмасы ветераннар советын Диплом белән бүләкләде. Рәисе Марс Исхаковка Ватан Геройларының исемен мәңгеләштерүдә өлеш кертүе өчен, шулай ук 75 яше уңаеннан Мактау грамотасы бирелгән. Россия Мәдәният министрлыгы тарафыннан да аңа Рәхмәт сүзе белдерелгән. Ветераннар советы рәисе урынбасары Николай Степановка Россия Иҗтимагый палатасы карары белән Мактау грамотасы бирелгән. Котлыйбыз!

Укучылар һөнәр сайлый

Тимәш мәктәбенең 9 “Б” сыйныфы укучылары һөнәри юнәлеш алу максатында, Лениногорск политехник колледжында булып кайттылар, дип хәбәр итә мәктәп сайты.

Алар анда колледж тормышы турында фильм караганнар. Укучылар алдында мастерлар, укытучылар һәм студентлар чыгыш ясаган. Аннары укыту кабинетларында, мастерскойларда булганнар. Егетләр эретеп ябыштыру эшендә үзләрен сынап та караган. Соңыннан укучыларны төшке ашка чакырганнар.

Җырлаулары ошаган

Мәдәният сараена йөрүче җырчы кызлар “Татнефть”нең “Рухият” фонды оештырган «Сандугач сайрар илем» балалар иҗаты фестивалендә уңышлы чыгыш ясады, дип хәбәр итә муниципалитет сайты.

Фестиваль «Җәлилнефть» идарәсенең «Дружба» лагерында үтте. Анда туксаннан артык бала катнашты. Безнекеләрдән «Вокал. Соло башкаруы» номинациясендә үз яшь төркемнәре арасында беренче урынны Эльвина Гаделшина алды, икенче урында – Анастасия Казанцева һәм Диләрә Еремеева.

Авыл яшьләре волейбол уйнады

Шөгердә районыбызның авыл яшьләре волейбол уйнады.

Барлыгы сигез команда катнашты, нәтиҗәләр түбәндәгечә: беренче урында – Иске Иштирәк, икенчедә – Кирлегәч, өченчедә Шөгер командасы. Призлы урын алган барлык командаларга Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсеннән бүләкләр һәм кубок тапшырылган.

Өйдән-өйгә йөрмиләр

Лениногорскида без пенсия фондыннан дип, өйдән-өйгә йөрүчеләр бар, алар мошенниклар, яисә дәүләтнеке булмаган пенсия фонды хезмәткәрләре, дип хәбәр иттеләр Пенсия фонды идарәсеннән.

Кайбер ышанучан кешеләр үзләре турында мәгълүмат бирә – документларын күрсәтә, хәтта ниндидер кәгазьләргә кул куйган очраклар бар икән. Лениногорск буенча Пенсия фонды идарәсе үзләреннән өйдән-өйгә йөрмәве турында хәбәр итә, төрле сораулар буенча халык бары тик пенсия фондының территориаль идарәсендә генә кабул ителә. Сак булыгыз!

РЕКЛАМА. ТӨРЛЕСЕННӘН. КОТЛАУ

Юбилеегыз белән!

Сарабиккол авылында яшәүче **Фәния Габделбарый кызы Ялакова** 1 февральдә гомер бәйрәмен - ярты гасырлык **туган көнен** бәйрәм итте.

Ул мәктәптә уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары вазыйфаларын башкара һәм балаларга география фәнен укыта.

Хәрмәткә лаек хезмәттәшебез! Сине туган көнең белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Сиңа ныклы исәнлек, хәерле озын гомер, иман байлыгы, җан тынычлыгы телибез. Син гадел дә, кешелекле дә, ышанычлы да. Тормыш иптәшең Рәстәм белән бергә балаларыгызның игеленген күреп, алар өчен шатланып, тигезлектә гомер итүегезне телибез. Салкын кыш аенда тусаң да, синнән һәрвакыт җылылык бәркелә. Һәркем белән уртак тел табасың, аларны аңлый беләсең. Һәрвакыт шундый булып кал.

Иң изге теләкләр белән
Сарабиккол мәктәбе коллективы

РЕМОНТ НА ДОМУ
холодильников, стиральных машин
Тел. 9-51-17, 8987-277-10-55 Рифкат
Реклама

ЕЛМАЕП АЛЫЙК

Берәүне ЮХИДИ хезмәткәре туктата:
– Ник номерсыз йөрибез?
–Мин аны яттан да беләм.

***

– Алло, матурым, беренче каналны кабыз әле.
– Йә, кабыздым.
– Анда нәрсә бара?
– «Давай поженимся».
– Мин риза, матурым.

***

– Кичә сездән урындык сатып алган идем, бүген ул таралып төште.
– Булмас! Мөгаен, аңа берәрегез утырып карагандыр...

***

Хатыны:
– Нәрсә, аш ошадымы?
– Дәшмә. Тагын бәхәс өчен сәбәп эзлисеңме?

***

– Мескен Галия...
– Нәрсә булган?
– И, бик матур туфли алган да, бер киеменә дә туры килми. Инде итәк алган иде, өстенә киергә блузкасы юк икән. Анысын да алып кайтты, сумка кирәк. Кичә яңа сумка алган иде, туфлиенә туры килми!

***

Берәү песиен урманга алып барып адаштырырга булган. Өч сәгатьтән песие кайтып керә, үзе күренми. Хатыны шалтыратып моңа:
– Карт, песи кайтты, син кайда?
– Адаштым!..

ТАБИГАТЬ ҺӘМ КЕШЕ

Монда кыш чыгалар

Розалия МОСТАФИНА фотосы

Шәһәрнең Добролюбов урамындагы сулыкта-буада салкын кыш көннәрендә үрдәкләр йөзеп йөри.

Моңарчы, түбән сулык боз белән капланганчы алар шунда йөзде. Хәзер бирегә күчкәннәр. Үзара сөйләшеп-бакылдашып, тирә-якка ямь өстәп йөзәләр. Шул тирәдән үтүче халык аларны ашата. Хәтта ашатырга дип махсус килүчеләр дә бар, кулларына ипи кисәкләре тотып төшүчеләр дә күренә.

АктанышЛес **ДОМА и БАНИ из бруса**
СЕЗОННОЕ СНИЖЕНИЕ ЦЕН

6х6 - 93 т.руб.
6х9 - 134 т.руб.
8х10 - 197 т.руб.
10х10 - 222 т.руб.
10х12 - 255 т.руб.
Возможно оформление кредита прямо в офисе
(АО ОТП Банк, лиц. № 2766 от 27.11.2014)
купившему полный комплект БЕНЗОПИЛА В ПОДАРОК
готовые проекты
А также комплектуем ПО ВАШИМ РАЗМЕРАМ
тел./ф: 8(85552)3-30-60
8-903-305-41-14
Доставка и монтаж за дополнительную плату
РТ, с. Актаныш, ул. Лесная, 25 (база Актанышлес)
E-mail: ilsur-70@mail. ru, сайт: Актанышлес.рф
Реклама

МЕХОВАЯ ВЫСТАВКА
5 февраля
с 10:00 до 19:00 час.
ГОЛОВНЫЕ УБОРЫ, ДУБЛЁНКИ
(мужские, женские, детские)

ШУБЫ
(норка, бобер, сурок, енот, нутрия, овчина)
СКИДКИ до 20%
КРЕДИТ Без первоначального взноса
ТОВАР СЕРТИФИЦИРОВАН
АКЦИЯ!!!*
Принеси старую шубу - получи скидку на новое изделие
* Подробности акции у продавцов
"Кировские меха" г.Киров
Кредит от "ОТП Банк" лицензия № 2766 от 04.03.2008г. выдана ЦБ РФ. Более подробные условия в точке продаж.
Распродажа бижутерии из натурального камня
Реклама

Доставка
Продаем
СЕНО, СОЛОМУ, ТЕЛЯТ
8-927-636-09-12, 8-960-396-77-71
Реклама

Электр счетчиклары алыштырабыз, урам ягына чыгарабыз. Өйдәге электр чыбыкларын алыштырабыз.
Тел. 6-27-00
Реклама

Продается
Двухкомнатная квартира, по ул. Ленина, 19 (с.Шугурово), 44,1 кв.м.
2 этаж, центр. Цена 950 тыс.руб.
Тел. 8987-173-04-86, 8927-466-83-15

ЭШКӘ ЧАКЫРАБЫЗ
«ЗАМАН СУЛЫШЫ» редакциясенә сайт белән эшләүче белгеч кирәк.
Телефоннар: 5-07-72, 8-917-222-68-94 Реклама

РЕКЛАМА: 5-39-59, 8-917-919-24-68

Газетны гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ
ZAMANSULYSHY.RU
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде

«Заман сулышы»
(«Дыхание времени»)
Лениногорск районы газеты
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир А.И.МИҢНЕБАЕВА
Тел.: 5-07-72

Редакция адресы:
423250, ТР, Лениногорск шәһәре, Тукай урамы, 3.
Эл. адресы: zaman5@yandex.ru
Телефоннар:
5-39-59 - кабул итү бүлмәсе, факс, бухгалтерия, реклама;
5-39-08 - җаваплы секретарь, корреспондентлар
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ 420097, Казан, Академическая ур., 2.

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсен күзәтү Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсендә ПИ №ТУ16 – 01037 номерлы таныклыгы белән 2013 елның 16 маенда теркәлде.
Газет «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
Басарга кул кую вакыты:
график буенча - 14.30,
чынлыкта - 14. 30.

Авторларның фикере редакциянең фикере белән тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы буларак чыгыш ясау мөмкинлеге юк.
Кулъязмаларга бәяләмә бирелми һәм кире кайтарылмый.
Реклама һәм белдерүдәге мәгълүматның дәреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
©Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.

Тираж – 1654
Газет чәршәмбе, җомга көннәрендә чыга.
Заказ №9665
Газетның индексы:
халык өчен – 16043
предприятие һәм оешмалар өчен – 16044
Сатуда бәясе ирекле. (16+)